ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

________________　　15.11.2023　　ПР-246　　　　№ ______

«Татарстан Республикасы Актаныш районы» муниципаль берәмлегендә балаларга бушлай мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүне, түләүсез өстәмә белем бирүне оештыру турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 14 июлендәге 473 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә мәҗбүри таләпләр турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 24 сентябрендәге 371-ФЗ номерлы федераль законнарга, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 04 августындагы 479-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 14 июлендәге ПР-473 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Актаныш районы» муниципаль берәмлегендә балаларга бушлай мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүне, түләүсез өстәмә белем бирүне оештыру турындагы нигезләмәгә (2019 елның 15 августындагы ПР-171 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 2.2.3 пунктчасында «мәктәпкәчә белем бирүнең тиешле якынча белем бирү программаларын исәпкә алып» сүзләрен «мәктәпкәчә белем бирүнең тиешле федераль белем бирү программасы» сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Мәгариф программаларының мәгариф оешмалары тарафыннан эшләнгән эчтәлеге һәм планлаштырыла торган нәтиҗәләре тиешле эчтәлектән һәм мәктәпкәчә белем бирүнең федераль программасының планлаштырыла торган нәтиҗәләреннән түбәнрәк булмаска тиеш;

1.2 2.3.4. пунктчасындада «социаль сәләтлелеккә» сүзләреннән соң «һәм һөнәри» сүзләрен өстәргә;

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Д.М. Әнвәровага йөкләргә.

Җитәкче　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.А.Ильясов

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 621DCE305601C88D15496913AD135909
Владелец: Ильясов Рустем Алмазович
Действителен с 10.04.2023 до 03.07.2024